ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

18.01.2022 — с. Соболевское — №1

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторын беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары гомуми исемлеген раслауның 10 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын расларга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы — О.Н. Майорова

Расланды
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 18 гыйнварыннан
1 карары белән

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

Әлеге тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторын беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары гомуми исемлеген раслауның 10 пункты нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә (Алга таба - исемлек, баш администратор) үзгәрешләр кертү механизмын һәм срокларын билгели.

Югары Ослан муниципаль районы бюджетының керемнәре классификациясенең кодларын билгеләү һәм структурасын үзгәртү принципларына үзгәрешләр кертү, шулай ук Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетының керем классификациясенең баш администраторларына беркетелгән кодлар исемлегенә үзгәрешләр кертелсә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетының 18.12.2021 ел, № 1 «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Башкарма комитетының бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертмичә башкарыла.

Исемлеккә үзгәрешләр федераль һәм төбәк законнарына бюджет керемнәрен классификацияләү кодларының баш администраторларына беркетелгән составына үзгәрешләр кертү өлешендә кертелә.